| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

31.08.2022 Казан ш. №821

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында эшсез гражданнарны хезмәт базарында социаль яраклаштыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 15 сентябрендәге 649 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында эшсез гражданнарны хезмәт базарында социаль яраклаштыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 15 сентябрендәге 649 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 28.09.2016 №549, 12.07.2018 №550, 10.09.2018 №842, 31.05.2019 №414, 16.11.2019 №1039, 15.05.2020 №297, 20.07.2020 №521, 28.09.2020 №675, 07.06.2021 №403, 27.10.2021 №794, 16.06.2022 №555 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
31.08.2022 ел, №821 боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында эшсез гражданнарны хезмәт базарында социаль яраклаштыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 15 сентябрендәге 649 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Боерыкның преамбуласында «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Эшсез гражданнарны социаль яраклаштыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең федераль дәүләт стандартын раслау турында» 2013 елның 9 гыйнварындагы 3н номерлы боерыгы белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Эшсез гражданнарны хезмәт базарында социаль яраклаштыру буенча халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру эшчәнлеге стандартын раслау турында» 2022 елның 27 апрелендәге 266н номерлы боерыгы белән» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасында хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль яраклаштыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1-3 бүлекләрне киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасында хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль яраклаштыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент), хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль яраклаштыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын, тәртибен һәм гамәлләр (административ процедуралар) эзлеклелеген билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр – законнарда билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнар (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### 2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль яраклаштыру.

### 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

2.2.1. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт оешмалары (алга таба – халыкның мәшгульлек үзәге, ХМҮ) тарафыннан күрсәтелә. Халыкның мәшгульлек үзәкләренә карата гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) гамәлгә ашыра.

Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлекләре территориясендә халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча күрсәтелә.

2.2.2. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тиешле хезмәтләр күрсәтергә хокуклы, тиешле белемгә һәм эш тәҗрибәсенә ия булган белгечләр (алга таба – шартнамә нигезендә җәлеп ителгән белгеч) тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәкләренә җәлеп ителә торган дәүләт хезмәтләренең бер өлешен (кирәк булса) күрсәтү рөхсәт ителә.

2.2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) һәм (яки) КФҮнең ерактагы эш урыны аша бирергә мөмкин.

КФҮ белгече тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм гаризаны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителми.

### 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль яраклаштыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә тора (Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 27 апрелендәге 266н номерлы боерыгы белән расланган Хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль яраклаштыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру эшчәнлеге стандартына (алга таба – Стандарт) 2 нче кушымта; (әлеге Регламентка 3 нче кушымта), ул түбәндәгеләрне үз эченә ала:

а) эш эзләү һәм актив тормыш позициясен формалаштыру, резюме төзү, эш бирүче белән эшлекле аралашу күнекмәләрен камилләштерү, коллективта үз-үзеңне презентацияләү һәм яраклаштыру күнекмәләрен камилләштерү буенча тәкъдимнәр (булган очракта);

б) үткәрелгән тест нәтиҗәләре (булган очракта);

в) күрсәтелгән сервисларның нәтиҗәләре, һәр сервис кысаларында чаралар исемлеген күрсәтеп (булган очракта);

г) сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планы тулы күләмдә үтәлмәгән очракта, кабат гариза бирү максатыннан халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итү тәкъдиме.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе «Работа в России» порталында теркәлә.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә «Работа в России» (https://www.trudvsem.ru/) бердәм платфрлы платформадан (алга таба – «Работа в России» порталы) файдаланып, шул исәптән Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы (http://www.uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Татарстан Республикасы порталы) аша электрон документ формасында;

мөрәҗәгать итүчегә шәхсән, кәгазь чыганакта.

## 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. «Работа в России» порталыннан файдаланып дистанцион форматта дәүләт хезмәте «Работа в России» порталында дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза кабул ителгәннән соң егерме эш көненнән дә соңга калмыйча күрсәтелә.

2.4.2. Халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килеп йөрү зарурлыгы булган очракта, дәүләт хезмәте «Работа в России» порталында гариза кабул ителгәннән соң утыз эш көненнән дә соңга калмыйча күрсәтелә.

2.4.3. Бәяләмә мөрәҗәгать итүчегә «Работа в России» порталыннан формалаштырылган көнне җибәрелә.

2.4.4. Мөрәҗәгать итүче КФҮ мөрәҗәгать иткән очракта, гаризаны халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшыру КФҮ белән халыкның мәшгульлек үзәге арасындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм чорларда, ләкин гаризаны КФҮ теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

2.4.3. Инвалид булып торган мөрәҗәгать итүчеләргә дәүләт хезмәте күрсәтү «Федераль инвалидлар реестры» (алга таба – ФИР) федераль дәүләт мәгълүмат системасында булган инвалидлык турында белешмәләр, ә тиешле белешмәләр булмаса, мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

ФИР аша инвалидлык турында кирәкле белешмәләрне алу мәшгульлек үзәге тарафыннан «Ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы) ярдәмендә мәшгульлек үзәге тарафыннан электрон документ рәвешендә җибәрелә торган ФРИ адресына ведомствоара гариза формалаштыру юлы белән халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан башкарыла.

ФИР системасыннан кирәкле белешмәләрне алу вакыты мөрәҗәгать итүче гариза тапшырган датадан башлап җиде эш көненнән артмаска тиеш.

## 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) турында

белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль рәвештә тапшыра торган документлар һәм мәгълүматлар:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (Стандартка 1 нче кушымта ) (әлеге Регламентка 2 нче кушымта) (алга таба –- гариза), «Работа в России» порталын, Бердәм порталны, Татарстан Республикасы порталын кулланып, КФҮ аша электрон документ формасында тапшырыла;

эшсез гражданинны теркәү вакытында «Работа в России» порталына мөрәҗәгать итүче тарафыннан кертелгән белешмәләр.

2.6.2. Электрон рәвештәге гариза халыкның мөрәҗәгать итүче тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гади электрон имза куллану турында» 2013 елның 25 гыйнварындагы 33 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гади электрон имза куллану кагыйдәләре нигезендә алынган гади электрон имза белән яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән яки көчәйтелгән квалификацияле булмаган, тикшерү сертификаты Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели торган электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада булдырылган һәм кулланыла торган имза белән имзалана.

Гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

«Работа в России» порталындагы шәхси кабинет аша;

Бердәм портал аша;

Татарстан Республикасы порталы аша;

КФҮ аша;

халыкның мәшгульлек үзәгенә «Работа в России» порталына, Бердәм порталга, Татарстан Республикасы порталына керүне тәэмин итеп, шәхсән килгән очракта.

Гариза мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән эшсез сыйфатында исәптә торган яисә халыкның мәшгульлек үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдиме белән риза булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәгенә бирелә.

2.6.3. Мөрәҗәгать итүче электрон формада гариза биргәндә булышлык күрсәтүне сорап, халыкның мәшгульлек үзәгенә яисә КФҮ мөрәҗәгать итә ала.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүчеләргә «Работа в России» порталына, Бердәм порталга һәм Татарстан Республикасы порталына керү мөмкинлеге бирелә, шулай ук кирәкле консультация ярдәме күрсәтелә.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән затта «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм атутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында исәпкә алу язуы булмаса, халыкның мәшгульлек үзәге яки КФҮ, халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итүче зат риза булган очракта, әлеге системада мөрәҗәгать итүченең процедуралар узып бетерүен тәэмин итә.

2.6.4. Халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән барган очракта, мөрәҗәгать итүче паспортын яисә аны алыштыра торган документны күрсәтә.

2.6.5. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан мөрәҗәгать итүче турында алына торган белешмәләр:

Организмдагы бозылган функцияләрне һәм яшәештәге чикләүләрне исәпкә алып, инвалид өчен медик-социаль экспертиза федераль дәүләт учреждениеләре (алга таба – МСЭ учреждениесе) тарафыннан киңәш ителә торган хезмәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлау өчен кирәкле, инвалидлык турындагы белешмәләрне үз эченә алган индивидуаль тернәкләндерү программасыннан өземтә, – ФИР аша.

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы. Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Әлеге дәүләт хакимияте органнары тарафыннан документлар һәм мәгълүматның тапшырылмавы (вакытында тапшырылмавы) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе була алмый.

### 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.

### 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килгән вакытта Россия Федерациясе гражданины паспортын яки аны алмаштыра торган документның, чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклый торган документларның, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклый торган документларның булмавы яки аларны күрсәтүдән баш тартуы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Гаризаны электрон рәвештә биргәндә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез юк.

2.8.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге очракларда туктатыла:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 2 ноябрендәге 1909 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2021, №46, 7707 ст.) белән расланган Эшсез гражданнарны теркәү кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган мөрәҗәгать итүчене теркәү исәбеннән төшергәндә;

гаризаны кире алган очракта;

әлеге Регламентның 3.17 пунктында каралган тәртиптә халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан билгеләнгән датада мөрәҗәгать итүчене социаль адаптацияләү сервисларын (чараларын) гамәлгә ашыруның индивидуаль планын килештерү өчен мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә килмәгән очракта;

белдерүдә күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәге белән үзара хезмәттәшлек итә башларга тиешле, халыкның мәшгульлек үзәге белдерүендә күрсәтелгән датадан башлап бер айдан артып киткән чорда мөрәҗәгать итүченең халыкның мәшгульлек үзәге белән хезмәттәшлек итмәве.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

## 2.10. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.10.1. Мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза «Работа в России» порталын кулланып, чират тәртибендә бирелә. Чиратта тору вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.10.2. Вакыты һәм датасы алдан килештерелгән очракта, мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә «Работа в России» порталын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны көтү вакыты биш минуттан артмаска тиеш.

Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән.

## 2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Гариза тапшырылган көнне.

2.11.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә теркәлә.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән хезмәт күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектлардан һәм күрсәтелә торган дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтләре күрсәтү мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны

рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) хезмәт һәм мәшгульлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүче халыкның мәшгульлек үзәкләре тарафыннан инвалидларга, башка затлар белән беррәттән, дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә комачаулый торган каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-ноктала хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2.12.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

## 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм чорлары турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү үрнәкләре турында мөрәҗәгать итүче өчен индивидуаль яки гавами (телдән яки язмача) мәгълүмат бирү мөмкинлеге (шәхси кабул иткәндә, телефон элемтәсе, электрон почта чараларын кулланып, массакүләм мәгълүмат чараларында мәкаләләр, мәгълүмати материаллары (брошюралар, белешмәлекләр, буклетлар һ.б.) нәшер итү юлы белән, «Работа в России» порталында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында мәгълүмат урнаштыру юлы белән);

мөрәҗәгать итүче өчен дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаларның һәм башка документларның үрнәкләрен алуны, шул исәптән аларны күчереп алу һәм электрон рәвештә тутыру мөмкинлеге белән дә, тәэмин итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтү вакытының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, шул исәптән телефон элемтәсе, электрон почта аша, «Работа в России» порталы, Бердәм портал һәм Татарстан Республикасы порталы, КФҮ, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында мәгълүмат алу мөмкинлеге;

КФҮ аша электрон гариза бирү мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре

түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү турында Россия Федерациясе законнарындагы мәҗбүри таләпләрнең, дәүләт хезмәте күрсәткәндә әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлеше;

дәүләт хезмәте күрсәтү чорларының үтәлүе;

әлеге Регламентта билгеләнгән административ процедураларның эзлеклелеге саклану;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезлелеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләсе буенча нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы.

2.13.3. Мөрәҗәгать итүченең ХМҮ белгечләре белән үзара хезмәттәшлек итү саны (шәхсән килгән очракта):

гаризаны электрон формада биргәндә булышлык күрсәтү – бер тапкырдан артыграк түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәткәндә тестлар узганда – ике тапкырдан артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.13.4. Мөрәҗәгать итүченең мәшгульлек үзәге белгечләре белән бәйләнешкә керү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

тестлар үткәрү өчен шәхсән килгән очракта – бер тапкырдан артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планын килештергәндә – бер тапкырдан артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

сервислар составында чараларны гамәлгә ашыру өчен шәхсән килгән очракта – бер тапкырдан артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

индивидуаль консультация үткәрү өчен шәхсән килгән вакытта – бер тапкырдан артык түгел.

2.13.5. Хезмәттәшлек итүнең дәвамлылыгы әлеге Регламент белән билгеләнә.

2.13.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү (консультация бирүдән һәм гариза кабул итүдән тыш) КФҮ аркылы гамәлгә ашырылмый.

Мөрәҗәгать итүче КФҮ мөрәҗәгать иткән очракта, гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә теркәлгән көннән соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

2.13.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Работа в России» порталындагы шәхси кабинеты аша, Бердәм порталда, Татарстан

Республикасы порталында, КФҮ аша алынырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтү, хезмәт күрсәтү тәртибе һәм башка документлар турындагы белешмәләрне карау «Работа в России» порталындагы шәхси кабинетында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында мөрәҗәгать итүчене алдан авторизацияләмичә башкарыла.

«Работа в России» порталындагы шәхси кабинетта, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында авторизация узганнан соң мөрәҗәгать итүче түбәндәге мөмкинлекләргә ия була: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны тапшыру, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында белешмәләр алу, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алу.

### 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. Мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән яки халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме белән халыкның мәшгульлек үзәгенә дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итә ала.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) «Работа в России» порталында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

б) «Работа в России» порталын, Бердәм порталны, Татарстан Республикасы порталын кулланып, КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирергә;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) «Работа в России» порталы, Бердәм портал, Татарстан Республикасы порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бәяләмә формасында алырга;

е) дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган «Работа в России» порталы, Бердәм портал, Татарстан Республикасы порталы ярдәмендә Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.3. Гариза Татарстан Республикасы порталы, Бердәм портал, «Работа в России» порталы, КФҮ аша җибәрелергә мөмкин.

2.14.4. Мөрәҗәгать итүче КФҮ мөрәҗәгать иткән очракта, гаризаны халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшыру КФҮ белән халыкның мәшгульлек үзәге

арасындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм чорларда, ләкин гаризаны КФҮ теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

2.14.5. Гаризаны төзү, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка рәвештә тапшыру зарурлыгыннан тыш, «Работа в России» порталында яки Бердәм порталда гаризаның электрон рәвешен тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.14.6. Мөрәҗәгать итүчеләрне халыкның мәшгульлек үзәгенә кабул итү өчен язу (алга таба – кабул итү өчен язу) Татарстан Республикасы порталы, халыкның мәшгульлек үзәге телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә халыкның мәшгульлек үзәгендә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә системада сорала торган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу барышында күрсәтелгән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта Татарстан Республикасы порталы яки халыкның мәшгульлек үзәге телефоны аша алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

2.14.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.8. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә «Работа в России» порталы кулланыла.

2.14.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

### 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Дәүләт хезмәте түбәндәге административ процедураларны (гамәлләрне) үз эченә ала:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдимне формалаштыру һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрү;

б) мөрәҗәгать итүченең гаризасын кабул итү;

в) мөрәҗәгать итүче тарафыннан тест үтү кирәклеген билгеләү, тестлар сайлау һәм билгеләү, тест нәтиҗәләрен эшкәртү;

г) мөрәҗәгать итүчене социаль яраклаштыру буенча сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыруның индивидуаль планын (алга таба – сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планы) төзү һәм мөрәҗәгать итүче белән килештерү;

д) сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планы нигезендә гражданинга социаль яраклаштыру буенча сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру;

е) социаль яраклаштыру буенча сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен эшкәртү һәм мөрәҗәгать итүчегә киңәшләр әзерләү;

ж) мөрәҗәгать итүчегә индивидуаль консультация бирү һәм кирәк булганда кабаттан яки өстәмә сервислар билгеләү;

з) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә формалаштыру һәм җибәрү;

и) техник хатаны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүче турында «Работа в России» порталындагы мәгълүматларны анализлау

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче турында «Работа в России» порталында булган белешмәләрне, шулай ук әлеге Регламентның 2.6.5 пунктында каралган ведомствоара гаризаларны җибәрү юлы белән алынган белешмәләрне анализлый.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне (мөрәҗәгать итүчене туры килерлек эш эзләү максатларында теркәгән, эшсез мөрәҗәгать итүчене теркәгән очракта) башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче турындагы мәгълүматларны анализлау.

3.3. Халыкның мәшгульлек үзәге, «Работа в России» порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим формалаштыра һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Үтәү вакыты: процедура тәкъдим формалаштырылган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим җибәрү.

3.4. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә «Работа в России» порталы ярдәмендә халыкның мәшгульлек үзәгенә дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдимне карау нәтиҗәләрен җибәрү турында хәбәр итә.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүченең тәкъдимнән баш тартуы яисә тәкъдим белән ризалашуы.

Үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдимне карау срогы билгеләнми.

3.5. Халыкның мәшгульлек үзәге «Работа в России» порталында мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдимнән баш тартуын терки.

3.6. Халыкның мәшгульлек үзәге «Работа в России» порталында мөрәҗәгать итүченең «Работа в России» порталындагы белешмәләрен анализлау нигезендә тест узу зарурлыгы яки кирәк булмавы турында карар кабул итә һәм теркәп куя.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче тарафыннан тест үтү кирәклеге яки кирәк булмавы турында карар.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүченең гаризасын кабул иткән көннән соң эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

3.7. Халыкның мәшгульлек үзәге, «Работа в России» порталыннан файдаланып, мөрәҗәгать итүчегә тест үткәрергә кирәк дигән карар кабул ителгән очракта:

а) мөрәҗәгать итүчегә тестлар сайлап алу һәм билгеләү эшен башкара;

б) мөрәҗәгать итүче белән килештерә һәм «Работа в России» порталыннан файдаланып, тест үтү датасын билгели, әгәр билгеләнгән тестлар «Работа в России» порталында булмаса;

в) мөрәҗәгать итүчегә билгеләнгән тестлар, аларны узу тәртибе һәм сроклары турында мәгълүматны үз эченә алган хәбәр җибәрә.

Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан билгеләнгән тестлар «Работа в России» порталында булган очракта, мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелгән тестларны «Работа в России» порталыннан файдаланып, хәбәрне алган көннән соң килгән өч календарь көн эчендә үтәргә кирәклеге турында белдерүдә хәбәр ителә.

Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан билгеләнгән тестлар «Работа в России» порталында булмаган очракта, мөрәҗәгать итүчегә хәбәрдә күрсәтелгән датада һәм вакыт эчендә тестлар узу өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килү кирәклеге турында белдерү белән хәбәр ителә.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тест узу вакыты һәм тәртибе турында мәгълүмат белән хәбәр җибәрү.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче карар кабул иткән көнне башкарыла.

3.8. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә «Работа в России» порталындагы тестларны узу өчен функциональ мөмкинлекләр бирә.

Процедураның нәтиҗәсе: тестны онлайн режимда узу һәм аның нәтиҗәләре белән танышу.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче тарафыннан тестлар үткән көнне башкарыла.

3.9. Мөрәҗәгать итүчегә билгеләнгән тестлар «Работа в России» порталында булмаса, халыкның мәшгульлек үзәге (яисә килешү нигезендә җәлеп ителгән белгеч) мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхси килгән очракта аның белән тест уздыра.

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә тест уздыру өчен шартнамә нигезендә белгечне яисә оешманы җәлеп итү турындагы белешмәләрне, шул исәптән әлеге шартнамә реквизитлары турындагы белешмәләрне дә, «Работа в России» порталына кертә.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәгендә тест узу.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

3.10. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче шәхсән килгән вакытта аның тестлар узу нәтиҗәләрен «Работа в России» порталында терки, тест

нәтиҗәләрен эшкәртә.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче шәхсән килгән вакытта аның тестлар узу нәтиҗәләрен эшкәртү һәм «Работа в России» порталында теркәү.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче тест үткән көнне башкарыла.

3.11. Мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә тестларны узу өчен белдерүдә күрсәтелгән датада һәм вакытта килмәгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге, «Работа в России» порталын кулланып, мөрәҗәгать итүче өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә кабат килү датасын һәм вакытын билгели, тиешле белдерүне мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә беренче тапкыр билгеләнгән датадан соң шәхси килмәгән көннән башлап 15 календарь көн дәвамында халыкның мәшгульлек үзәгенә иң күбе ике тапкыр кабат килү көнен билгели.

Мөрәҗәгать итүче тестларны узу өчен халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан билгеләнгән даталарда беренче тапкыр шәхсән килмәгән көннән башлап 15 календарь көн дәвамында халыкның мәшгульлек үзәгенә килмәгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүченең тестларны узу өчен килмәве турындагы белешмәләрне «Работа в России» порталында терки.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче тестларны узу өчен килмәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүченең халыкның мәшгульлек үзәгенә кабат килү ңатасын һәм вакытын билгеләү.

3.12. Әлеге Регламентның 3.8 һәм 3.10 пунктларында каралган тәртиптә халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан формалаштырылган мөрәҗәгать итүчегә тестлар уздыру нәтиҗәләре нигезендә халыкның мәшгульлек үзәге әлеге Регламентның 3.7-3.11 пунктларында каралган административ процедураларны (гамәлләрне) яңадан гамәлгә ашыру турында карар кабул итә.

Үтәү вакыты: процедура тест нәтиҗәләрен эшкәртү көненнән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: административ процедураларны (гамәлләрне) кабат башкару кирәклеге турында карар кабул итү.

3.13. Халыкның мәшгульлек үзәге әлеге Регламентка 4 нче кушымта нигезендә сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планын төзи.

Сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планы түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала: мөрәҗәгать итүчегә билгеләнгән сервислар исемлеге, чаралар исемлеге, һәр чараны үткәрү формасы (турыдан-туры яки дистанцион, индивидуаль яки төркемле), һәр чараны уздыру датасы һәм вакыты, турыдан-туры чараларны уздыру урыны, дистанцион чара уздырылачак интернет-ресурска тоташу өчен сылтама.

3.14. Халыкның мәшгульлек үзәге түбәндәге түбәндәге мәгълүматны исәпкә алып сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планын төзи:

мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган яисә ведомствоара гаризалар нигезендә, шул исәптән электрон хезмәттәшлек итүнең бердәм системасын кулланып, халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан алынган документлар һәм белешмәләр нигезендә «Работа в России» порталына мөрәҗәгать итүче турында

туры килә торган эшне эзләү максатларында әлеге мөрәҗәгать итүчене теркәгәндә, эшсез мөрәҗәгать итүчене теркәгәндә кертелгән белешмәләр;

«Работа в России» порталында булган, мөрәҗәгать итүчегә тестлар уздыру нәтиҗәләре;

«Работа в России» порталында автомат рәвештә формалаштырылган, киңәш ителә торган сервислар (чаралар) исемлеге;

Үтәү вакыты: процедура түбәндәге көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла:

мөрәҗәгать итүченең гаризасын кабул итү (халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан тест узу кирәк булмавы турында карар кабул ителгән очракта);

мөрәҗәгать итүче тарафыннан тестларны үтеп бетерү (бердәм цифрлы платформада тестлар билгеләнгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен);

тест нәтиҗәләрен эшкәртү (турыдан-туры тест уздыру билгеләнгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен);

тест уздыруның гомуми срогы бетү (тестларны тулысынча яки өлешчә узып бетмәгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен);

мөрәҗәгать итүчегә индивидуаль консультация бирү (кабат яки өстәмә сервислар билгеләгән очракта).

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче өчен сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планын формалаштыру.

3.15. Халыкның мәшгульлек үзәге, сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планын формалаштыру нәтиҗәләре буенча, «Работа в России» порталын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләрне җибәрә:

килештерү өчен сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планын;

сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планын формалаштыру көненнән соң килгән өч эш көненнән дә соңга калмыйча, «Работа в России» порталы ярдәмендә халыкның мәшгульлек үзәгенә планны килештерү яки аны эшләп бетерү кирәклеге турында белдерү.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүчегә планны килештерү турында яки аны эшләп бетерү кирәклеге турында мәгълүмат бирелгән көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче белән сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планын килештерү һәм «Работа в России» порталында мөрәҗәгать итүче тарафыннан сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планын килештерү турында мәгълүмат теркәү.

3.16. «Работа в России» порталына мөрәҗәгать итүчедән планны эшләп бетерү кирәклеге турында мәгълүмат алынган очракта яисә әлеге Регламентның 3.15 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланган көннән башлап халыкның мәшгульлек үзәге:

а) мөрәҗәгать итүче белән гаризада күрсәтелгән телефон номеры буенча дистанцион формада сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планы буенча фикер алышу өчен элемтәгә керә;

б) сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планына кирәкле үзгәрешләрне кертә һәм «Работа в России» порталында килештерү нәтиҗәләрен билгели;

в) мөрәҗәгать итүчегә сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планын кабат килештерүгә җибәрә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүчедән планны эшләп бетерү кирәклеге турында мәгълүмат бирелгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планын килештерү өчен кабат җибәрү.

3.17. Гаризада күрсәтелгән телефон номеры буенча мөрәҗәгать итүче белән сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планы турында фикер алышу мөмкинлеге булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчедән планны эшләп бетерү кирәклеге турындагы мәгълүмат бердәм цифрлы платформага алынган очракта яисә әлеге Регламентның 3.15 пунктында күрсәтелгән срок беткән көннән башлап, «Работа в России» порталын кулланып, күрсәтелгән датада һәм вакытта сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планы турында фикер алышу өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә килү кирәклеге турында мөрәҗәгать итүчегә белдерү җибәрә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүчедән планны эшләп бетерү кирәклеге турында мәгълүмат «Работа в России» порталына алынган көннән соңгы киләсе бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә халыкның мәшгульлек үзәгенә килү кирәклеге турында белдерү җибәрү.

3.18. Мөрәҗәгать итүче килгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче белән сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планы турында фикер алыша. Фикер алышу нәтиҗәләре буенча халыкның мәшгульлек үзәге, кирәк булганда, сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планына төзәтмәләр кертә һәм аны «Работа в России» порталыннан файдаланып, аны мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Үтәү вакыты: процедура план буенча фикер алышкан көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планын төзәтү һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрү.

3.19. Мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планын килештерү өчен белдерүдә күрсәтелгән датада һәм вакытта килмәгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге, «Работа в России» порталын кулланып, мөрәҗәгать итүче өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә кабат килү датасын һәм вакытын билгели, тиешле белдерүне мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә беренче тапкыр билгеләнгән датадан соң шәхси килмәгән көннән башлап 15 календарь көн дәвамында халыкның мәшгульлек үзәгенә иң күбе ике тапкыр кабат килү көнен билгели.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүченең башта билгеләнгән шәхсән килү көненнән соң эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүченең халыкның мәшгульлек үзәгенә кабат килү ңатасын һәм вакытын билгеләү.

3.20. Мөрәҗәгать итүче сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планын килештерү өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә беренче тапкыр билгеләнгән датага шәхсән килмәгән көннән башлап 15 календарь көн эчендә халыкның мәшгульлек үзәгенә килмәгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүченең килмәве турындагы белешмәләрне «Работа в России» порталында терки, дәүләт хезмәтен күрсәтү туктатыла, бу хакта халыкның мәшгульлек үзәге «Работа в России» порталын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә тиешле белдерүне җибәрә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче хезмәтләрне (чараларны) гамәлгә ашыру планын килештерү өчен килергә тиеш булган көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: «Работа в России» порталын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктату турында белдерү җибәрү.

3.21. Сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыруның килештерелгән планын мөрәҗәгать итүче «Работа в России» порталыннан карый ала.

3.22. Халыкның мәшгульлек үзәге сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планы нигезендә сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыруны тәэмин итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында түбәндәгеләргә юнәлдерелгән сервислар гамәлгә ашырыла:

мөрәҗәгать итүчене эш эзләү методларына һәм ысулларына, эш эзләү технологияснә, резюме төзү технологиясенә, эшкә урнашу мәсьәләләре буенча эш бирүче белән сөйләшүләр үткәрү методикасына өйрәтү, әңгәмә үткәрүне оештыруны да кертеп;

эшлекле аралашу күнекмәләрен камилләштерү һәм эш бирүче белән әңгәмәләр уздыру, үз-үзеңне презентацияләү, актив тормыш позициясен формалаштыру;

яңа эшкә чыгу, коллективка яраклашу, яңа эш урынына беркетү һәм карьераны планлаштыру, һөнәри вазыйфаларны башкару белән бәйле мәсьәләләр буенча фикер алышу.

Сервисларны гамәлгә ашыру кысаларында тренинглар, индивидуаль һәм төркемле консультацияләр, вебинарлар, лекцияләр һәм башка чаралар үткәрелергә мөмкин.

3.23. Мәшгульлек үзәге сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру өчен белгечне яки оешманы шартнамә нигезендә җәлеп иткән очракта, бу хактагы мәгълүматны, шул исәптән тиешле шартнамәнең реквизитлары турындагы мәгълүматларны да кертеп, халыкның мәшгульлек үзәге «Работа в России» порталына кертә.

3.24. Халыкның мәшгульлек үзәге:

а) сервислар (чаралар) үткәрү нәтиҗәләрен анализлый;

б) мәгълүматны үзләштерү һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан күнекмәләр алуны бәяләүне дә кертеп, сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен рәсмиләштерә һәм «Работа в России» порталына кертә;

в) сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен исәпкә алып, мөрәҗәгать итүче өчен тәкъдимнәр әзерли;

г) кирәк булган очракта, мөрәҗәгать итүче белән фикер алыша һәм киңәшләрне аңлата, аларны «Работа в России» порталына кертә һәм дәүләт

хезмәте күрсәтү турында бәяләмәне дә өсти;

д) мөрәҗәгать итүчегә сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планы белән каралган хезмәтләрне (чараларны) гамәлгә ашыру планы белән каралган эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашыру турында белдерү җибәрә.

Мөрәҗәгать итүче сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планында күрсәтелгән срокта халыкның мәшгульлек үзәгенә килмәгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүченең чарага килмәве турындагы белешмәләрне бердәм цифрлы платформада терки.

3.25. Сервисларны гамәлгә ашыру тәмамланганнан соң «Работа в России» порталында автомат рәвештә белдерү формалаштырыла һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә, анда түбәндәгеләр була:

а) хезмәт базарында социаль яраклаштыру мәсьәләләре булган очракта, индивидуаль консультация алу тәкъдиме;

б) консультация алу өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итү тәртибе;

в) мөрәҗәгать итүче консультация алу өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итә ала торган срок, ул мөрәҗәгать итүче тәкъдимне алган көннән соң өч эш көне чикләрендә билгеләнә.

3.26. Мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә консультация алу максатында мөрәҗәгать иткән очракта, консультация бирү өчен мөрәҗәгать итүченең халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килү датасын һәм вакытын мөрәҗәгать итүче белән килештерә.

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче белән килештерелгән халыкның мәшгульлек үзәгенә килү датасын һәм вакытын «Работа в России» порталында терки, «Работа в России» порталыннан файдаланып, консультация үткәрү өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итүченең шәхсән килү вакытын һәм датасын күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчегә белдерү җибәрә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче тәкъдимне алган көннән соң килгән өч эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче белән халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килүе турында килештерелгән дата һәм вакыты һәм «Работа в России» порталын кулланып, консультация үткәрү өчен мөрәҗәгать итүчегә белдерү җибәрү.

3.27. Индивидуаль консультация халыкның мәшгульлек үзәгендә белдерүдә күрсәтелгән дата һәм вакыт эчендә үткәрелә.

Халыкның мәшгульлек үзәге «Работа в России» порталында индивидуаль консультация нәтиҗәләрен терки.

Индивидуаль консультация йомгаклары буенча халыкның мәшгульлек үзәге, мөрәҗәгать итүченең ризалыгы белән, әлеге Регламентның 3.13-3.22 пунктларында каралган административ процедураларны (гамәлләрне) кабат узу кирәклеге турында карар кабул итә ала. Халыкның мәшгульлек үзәге, сервисларны (чараларны) гамәлгә ашыру планы кабат формалаштырылган очракта, әлеге Регламентның 3.14 пунктында күрсәтелгән мәгълүматтан тыш, мөрәҗәгать итүче белән индивидуаль консультация нәтиҗәләрен исәпкә ала.

3.28. Мөрәҗәгать итүче индивидуаль консультация алу өчен белдерүдә

күрсәтелгән датада һәм вакытта халыкның мәшгульлек үзәгенә килмәгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге килмәү очрагын «Работа в России» порталында терки.

Мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 3.25 пунктының «б» пунктчасында күрсәтелгән срокта индивидуаль консультациягә язылмаган икән, халыкның мәшгульлек үзәге, бердәм цифрлы платформаны кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә формалаштыра.

Үтәү вакыты: процедура индивидуаль консультация уздырылган көннән соңгы яисә әлеге Регламентның 3.25 пунктының «б» пунктчасында күрсәтелгән срок беткән көннән башлап (мөрәҗәгать итүче индивидуаль консультациягә язылмаган булса), яисә индивидуаль консультация билгеләнгән көннән башлап (мөрәҗәгать итүче индивидуаль консультациягә килмәгән очракта) өч эш көненнән дә соңга калмаган срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә формалаштыру.

3.29. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы бәяләмә мөрәҗәгать итүчегә автомат рәвештә, «Работа в России» порталын кулланып, формалаштырылган көнне җибәрелә.

Үтәү вакыты: процедура дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы бәяләмәне формалаштыру көнендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә җибәрү.

3.30. Әлеге Регламентның 2.8.3 пунктында каралган нигезләр буенча дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылган очракта, мөрәҗәгать итүче тестларны узганнан соң һәм (яки) сервисларны (чараларны) гамәлгә ашырганнан соң, халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә формалаштыра һәм «Работа в России» порталын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Үтәү вакыты: процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигез булган вакыйга килеп җиткән көннән соңгы өч эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә җибәрү.

3.31. техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны яки шуңа охшаш хатаны) төзәтү.

Техник хатаны төзәтү мөрәҗәгать итүче тарафыннан, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 1 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза бирелгәндә гамәлгә ашырыла.

3.31.1. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмәне үзгәртеп рәсмиләштерә;

- мөрәҗәгать итүчегә аның гаризасында күрсәтелгән ысул белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмәне яңадан рәсмиләштерү турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, дәүләт хезмәте күрсәтү турында яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә турында хәбәр итү.»;

4 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Административ регламентның үтәлешен контрольдә тоту формалары»;

4.2 пунктта «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2010 елның 8 ноябрендәге 972 номерлы боерыгы белән расланган Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар (физик затлар һәм эш бирүчеләр) регистрын алып бару тәртибенең» сүзләрен «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2021 елның 6 декабрендәге 871н номерлы боерыгы белән расланган Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затларның регистрларын алып бару тәртибен, шул исәптән аларга белешмәләр кертү тәртибен, чорларын һәм белешмәләр рәвешен, шулай ук халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрларында булган мәгълүмат төрләре исемлегенең» сүзләренә алмаштырырга;

4.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның (белешмәлек) кушымтасында китерелгән.»;

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләр, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе;

5.2 пунктның икенче абзацында «дәүләт хезмәте» сүзләреннән соң «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) $15^1$ статьясында күрсәтелгән» сүзләрен өстәргә.»;

2 нче, 3 нче кушымталарны киләсе редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасында эшсез гражданнарны хезмәт базарында социаль яраклаштыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

үрнәк

Хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль яраклаштыру буенча
дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

2. Җенесе

3. Туган көне

4. Гражданлыгы

5. ИНН

6. СНИЛС

7. Шәхесне раслаучы документ төре

8. Шәхесне раслаучы документ сериясе, номеры

9. Шәхесне раслаучы документны бирү датасы

10. Шәхесне раслаучы документ кем тарафыннан бирелгән

11. Элемтә ысулы:

а) телефон

б) электрон почта адресы (булган очракта)

12. Хезмәт күрсәтү урыны:

а) Россия Федерациясе субъекты

б) халыкның мәшгульлек үзәге

Мәгълүматларны раслау:

☐ Әлеге мөрәҗәгать буенча карар кабул итү һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү максатларында минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык белдерәм, шул исәптән түбәндәгеләр өчен дә:

- әлеге мөрәҗәгатьне дәүләт органына, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләренә яисә мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү аның компетенциясенә карый торган вазыйфаи затка җибәрү;

- әлеге мөрәҗәгать буенча карар кабул итү һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү максатыннан өченче затларга шәхси мәгълүматларымны тапшыру.

Татарстан Республикасында эшсез гражданнарны хезмәт базарында социаль яраклаштыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

үрнәк

Хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль яраклаштыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә

___________________________________________________________________________

(гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль яраклаштыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтелде.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә:
а) тест билгеләнде һәм үткәрелде:

| т/с | Тестның исеме | Узу турында белешмәләр | Үткәрү формасы |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |

Тест нәтиҗәләре:
б) сервис билгеләнде һәм гамәлгә ашырылды (барлык гамәлгә ашырылган сервислар буенча мәгълүмат кертелә)

| т/с | Чараның атамасы | Узу турында белешмәләр | Үткәрү формасы |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |

Сервисны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре:
Киңәш ителде:

Халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениесе хезмәткәре

(вазыйфа) (имза) (фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))

«__» ___________ 20__ ел.